**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кара Күл торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«01» ноябрь 2023 ел № 1

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 1 ноябрендә узган: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кара Күл торак пункты территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 11000 сум күләмендә үзара салым акчасын кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлү белән килешәсезме

1) авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунтлы таш салу, шул исәптән Кара Күл торак пунктында төзелеш контроле өчен дә түләү.

2) Кара Күл торак пунктында күперне ремонтлау.

3) Кара Күл торак пунктында скважинаны бораулау һәм суүткәргеч төзү, күзәтү коелары һәм янгын гидрантлары төзү мәсьәләсе белән халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 25 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 25 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 25 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге Кара Күл авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныrга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Гайтән авыл җирлеге Кара Күл торак пункты территориясендә теркәлгән һәм яшәүче һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 11000 сум күләмендә үзара салым акчасын кертү һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлү белән килешәсезме

авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту һәм грунтлы таш салу, шул исәптән Кара Күл торак пунктында төзелеш контроле өчен дә түләү.

2) Кара Күл торак пунктында күперне ремонтлау.

3) Кара Күл торак пунктында скважинаны бораулау һәм суүткәргеч төзү, күзәтү коелары һәм янгын гидрантлары төзү мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Кара Күл торак пункты мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Гайтән авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Н.В.Авдеева
Гайтән авыл җирлеге башлыгы: Н.В.Авдеева